РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«27» октября 2021 с. Тюлячи № 271

## 2022 елга Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты нигезендә, ДБУ «Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» нең 2021 елның 5 октябрендәге 01/1887 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Теләче муниципаль районының гомуми белем бирү оешмалары һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләре каршындагы интернатларда тәрбияләнүчеләрне тотуга норматив чыгымнарны кушымта нигезендә расларга.
2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының финанс-бюджет палатасына (Яхин Р.Р.) әлеге карарның 1 пункты белән расланган мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә мәгариф оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2022 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы-район Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы Б. Г. Гайнетдиновка йөкләргә.

Җитәкче И. Х. Хәмидуллин

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының «__» ___________ 20___ № ____ карарына кушымта

Теләче муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне тотуга НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР

| Гомуми белем бирү оешмасының тибы һәм төре | Территориаль урнашу урыны | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | авыл җирлеге | 98753 |
| Гомуми белем бирү интернат-мәктәбе | авыл җирлеге | 148363 |

Эшләр идарәчесе Һадиев И. Т.